# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында минималь куллану бюджеты турында

Әлеге Закон минималь куллану бюджетын эшләү һәм раслау, шулай ук республикада җәмгыяви-икътисадый сәясәт өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл иткәндә аны куллану өчен хокукый нигез билгеле.

**<u>1 статья.</u> Минималь куллану бюджеты төшенчәсе һәм аның составы**

Минималь куллану бюджеты кешенең актив физик сәләтен һәм эш көчен торгызу өчен кирәк булган азык-төлек продуктлары, озак куллану товарлары, хезмәт күрсәтүләр җыелмасының нисбәтләнгән хакыннан һәм салымнардан гыйбарәт.

Минималь куллану бюджеты хакының зурлыгы Татарстан Республикасы буенча, Татарстан Республикасы төбәкләре буенча һәм шәһәр, авыл халкының төп җәмгыяви-демографик төркемнәре буенча уртача җан башына гамәлдәге куллану бәяләре турында дәүләт статистикасы мәгълүматлары нигезендә билгеләнә.

2 статья. Минималь куллану бюджетын билгеләү

Минималь куллану бюджеты түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- агымдагы җәмгыяви-икътисадый сәясәтне гамәлгә ашыру һәм киләчәк өчен төзү;

- хезмәт өчен түләүнең, пособиеләрнең һәм башка җәмгыяви түләүләрнең күләмнәрен билгеләү;

- республика халкының тормыш дәрәҗәсе үзгәрешен анализлау һәм күзәллау;

- республика гражданнарының матди тәэмин ителеше дәрәҗәсен бәяләү;

- халыкны җәмгыяви яклау программаларын гамәлгә ашыру.

3 статья. Минималь куллану бюджетының составын билгеләү

Минималь куллану бюджетының составы, Татарстан Республикасының җәмгыяви-икътисадый үсешен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан, Татарстан һөнәр берлекләренең республика советы белән берлектә, кимендә елына бер мәртәбә яңадан карала.

4 статья. Минималь куллану бюджетыннан файдалану

Төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләрдә хезмәткәрнең минималь хезмәт хакы минималь куллану бюджеты хакының зурлыгыннан түбән була алмый.

Пособиеләрнең һәм башка җәмгыяви түләүләрнең күләмнәре законнар һәм башка норматив актлар нигезендә минималь куллану

бюджеты күләменә туры китереп билгеләнә.

<u>5 статья.</u> Минималь куллану бюджеты турындагы мәгълүматларны бастырып чыгару

Минималь кулланы бюджеты хакының әурлыгы һәм составы массакүләм мәгълүмат чараларында даими рәвештә басылып чыга.

<u>6 статья.</u> Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

Әлеге Закон 1994 елның 1 июленнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 8 июне
N 2152-XII